МНОГОПРОФИЛЬНАЯ
ШКОЛА №181
Казан шәһәре Совет районы “Күп профильле 181 нче мәктәп”
Апрель-май 2020 ел

# «Күкнең җиденче катында»

**БУ САНДА:**

*12 нче апрель-Космонавтика көне*
*Мәктәп яңалыклары*
*26 нчы апрель- Г.Тукай бәйрәме*
*1нче апрель- Көлке көне*

## *12нче апрель-Космонавтика көне!*




12 нче апрель - Космонавтика көне - кешелек тарихының истәлекле датасы. Бу көнне космоска кешенең беренче очуы ясалды.

Юрий Гагарин... Космосның батыр йөрәкле Рыцаре, илебезнең данлыклы улы. Кыска гына вакыт эчендә күккә менә, Кояш системасының барлык планеталарын тикшерә, әмма беренче очыш авыр һәм куркыныч була.

-1961 нче елның 12 нче апреле. Бу дата кешелек тарихына мәңгелеккә кереп калды.

Язгы иртәдә көчле ракета җир йөзенең беренче космонавты - Советлар Союзы гражданины Юрий Гагарин белән тарихта беренче “Восток” космик кораблен орбитага чыгарды.

Беренче космик очыш 108 минут дәвам итте. Безнең көннәрдә, орбиталь космик станцияләрдә күп экспедицияләр кылган вакытта, ул кыска булып тоела.

Әмма бу минутларның һәрберсе билгесез нәрсәләрнең ачышы булып тора.

### “Кеше галәмдә”.

Зәңгәр күктә кояш балкып, янып тора.
Энҗе нурлар җир йөзенә тамып тора.
Куанышып кошлар сайрый агачларда,
Әйтерсең лә бүген генә яз башлана.
Мондый язлар һәр күңелгә сеңеп калыр.
Алар тагы матурланып кабатланыр.
Мәскәү сөйли... Башкалабыз хәбәр итә;
Таныш диктор горурланып сөйләп китә.
- 1961 нче елның 12 нче апреле –
Кеше галәм киңлегенә очты бүген!
Шатланмыйча нишләсен соң безнең күңел!
Тын да алмый тыңлап торгач диктор сүзен,
Сәеррерәк сизә икән һәркем үзен.
-Кеше галәмдә! Бу нинди яхшы!
Димәк, ул аның ишеген ачты.
Юрий Гагарин – исеме аның.
Ул хәбәр итә биектән барын:
-Таулар, елгалар, шәһәрләр күркәм:
Дала һәм кырлар ямь-яшел үлән.
Ул, галәм гизеп исән-сау төште.
Ни бар соң җирдә кешедән көчле!

# Мәктәп яңалыклары...

## Дистанцион укыту режимы



6 нчы апрельдән мәктәбебез дистанцион укыту режымына күчте. Дистанцион укыту шартларында мәктәпләрдә дәресләр, дәрестән тыш эшчәнлек 30 минут бара.

Дәресләр 9.00 сәгатьтә башлана.

Түбәндәге платформалар һәм ресурслар популяр "Я Класс", Яндекс дәреслек, РЭМ, Укы.ру, Zoom, Ватсап, "В Контакте" һәм электрон Почта.

Әгәр элек аз тәэмин ителгән гаиләләрдә тәрбияләнүче һәм мөмкинлекләре чикле балалар өчен ташламалы туклану оештырылган булса, хәзер дә алар өчен азык-төлек жыелмасы рәвешендә 5 уку көненә 1 жыелма исәбеннән "коры пайкалар" бирелә.

## Хәтер китабы



Мәктәбебез Бөек Жиңүнең 75 еллыгы уңаеннан, "Хәтер китабы"на сугыш ветераннарын барлап, альбом чыгара.

Анда укучыларның Жиңү өчен фронтта һәм тылда көрәшкән әби-бабалары фотосурәтләре, алар турында белешмәләр урын алачак.

Белешмәләрне жыю дәвам итә.

Шулай ук, Жиңүнең 75 еллыгына багышлап, Республикабыз күләмендә төрле бәйгеләр уздырыла.

## "Жиңү открыткалары" проекты




РФ Президентының Идел буе федераль округы буенча вәкаләтле вәкиле башлангычы белән Бөек Жиңүнең 75 еллыгына карата "Жиңү открыткалар"ы күләмле халык проекты гамәлгә ашырыла.

Открыткалар Бөек Ватан сугышында бөтен халыкның Жиңүенә багышланган. Открыткалар тупланмасы даими рәвештә тулыланып тора.

Рәсемнәр һәм коллажлар, аппликацияләр һәм компьютер графикасы - эшләрне башкару стиле төрле, ләкин барлык открыткалар да халкыбызның батырлыгы турында истәлекне берләштерә.

Безнең мәктәп укучылары да бу проектта катнаша, аларга уңышлар телибез!

## 26 нчы апрель -
## Габдулла Тукай туган көн




### Габдулла Тукай.

*Һәр милләттә йөзек кашы булырдай кешеләр бар. Татар тарихында да андыйлар аз түгел. Ләкин халык язмышында зур үзгәрешләр китереп чыгарган XX гасырга күз ташласак, татар аңына, татар рухына Тукай кадәр зур йогынты ясаган бүтән шәхесне очрата алмабыз. Менә хәзер, инде яңа гасырны ваклаганда, шикләнмичә әйтергә мөмкин: XX гасыр Тукай йолдызлыгы астында үткән, шул йолдыз юлыбызны яктыртып торган.*

*Ркаил Зәйдулла.*









**Тукай туган көн-**
**Туган тел көне.**

И туган тел, и матур тел,
әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән
әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! һәрвакытта
ярдәмең белән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган
иң элек кылган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
әткәм-әнкәмне, ходам!

Г. Тукай







## Укучыларыбыз ясаган рәсемнәр












## Көлке бәйрәме кайчан барлыкка килгән?

Көлке бәйрәме кайчан барлыкка килгән?

Бу традиция борынгы заманнарда язны каршылау бәйрәме булып саналган. Бу көнне кешеләр кышның усал өрәген сурәтләүче карачкыны жирләгәннәр. Аның үлеменә кем гаепле икәнен белмәсен өчен анда катнашучыларның барысы да маска кигәннәр. Шуннан бирле 1 апрельдә алдау гадәте кергән. Бу көн юмор, көлү, күңел ачу...

1 апрель шаяртулары Россиядә Петр 1 заманыннан бирле билгеле. Бу көнне Россиядә генә түгел, башка илләрдә дә билгеләп узалар.

Англиядә бер-берсенә шаярулы посылкалар җибәрәләр. 1860 елның 1 апрелендә Лондонда бик зур "шаяру" була. Әлеге көнне йөзләгән кеше Тауэрда ак арысланнарны юындыру тантанасына чакыру ала. Тауэр капкасы янында иртәдән кичкә кадәр "тантана" башланганын көтәләр. Ниһаять, башларына барып җитә: шаяртканнар икән.

Франциядә берәр кешенең аркасына сиздермичә генә кәгазь балык эләктереп куялар.

Австралиядә көнне кычкырып көлүдән башлыйлар. Иртән иртүк радиодан кукумарра дигән кошның кычкыруы язылган пленканы куялар. Аның тавышы бертуктаусыз көлүгә ошаган.

Германия һәм Австралиядә 1 апрельне уңышсыз көн дип санаганнар. Имеш бу көндә туган кешенең тормышы барып чыкмый.

Авылларда яңа эш башламаганнар, көтүне дә кумаганнар. Өлкәннәр һәм бала-чагалар бер-берсен үти алмаслык йомышлар кушып алдалаганнар.

Хәзер дә Россиядә бу бәйрәмне яраталар. "Юмор һәм көлүнең башкаласы" дип Одесса шәһәрен саныйлар. Анда ел саен 1 апрельдә Юморина бәйрәмен үткәрәләр.

Хәзер бу бәйрәм турында белмәгән кеше юк. Халык 1 апрельдә генә түгел, көндәлек тормышта да кешләрнең күңелләрен күтәреп йөртүче Хуҗа Насретдин, Алдар кебек үзе тапкыр әкият геройларын тудырган.

МНОГОПРОФИЛЬНАЯ
ШКОЛА №181

**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

**Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.

**Редколлегия әгъзалары:**
Мәхмүтова Мәдинә, Корчагина Яна, Вәлиева Диләрә, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәликә